# ШОМЫРТ ЧӘЧӘКЛӘРЕ АК КЫНА

*ХӨСНУЛ ВӘЛИУЛЛИН музыкасы*
*ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ сүзләре*

Бакчаларга тулган шомырт исе
Тәрәзәдән кергән өйләргә.
Исереп бер шомырт исләреннән,
Исереп бер яшьлек хисләреннән,
Җырлыйк әле шушы көйләргә...

Шомырт чәчәкләре ак кына,
Сөюләрен булса хак кына.
Сөенешеп йөрер чак кына...

Чыгыйк әле кырга икәүләшеп,
Дөнья җитә миңа син булгач;
Ник карыйм ди ятлар күзенә мин,
Ник карыйм ди кеше сүзенә мин,
Икебезнең йөрәк тиң булгач!

Шомырт чәчәкләре ак кына,
Сөюләрең булгач хак кына,
Сөенешеп йөрер чак кына.